МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

08.05.2019 г.Казань № 342

Боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 29 маеда 5590 номеры белән теркәлде

«Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы вәзгыять турында мәгълүмат җиткерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 16 сентябрендәге 654 номерлы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы вәзгыять турында мәгълүмат җиткерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы вәзгыять турында мәгълүмат җиткерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча эшләрне камилләштерү максатларында боерык бирәм:

«Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы вәзгыять турында мәгълүмат җиткерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 16 сентябрендәге 654 номерлы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән (2016 елның 16 маендагы 263 номерлы, 2018 елның 19 сентябрендәге 891 номерлы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы вәзгыять турында мәгълүмат җиткерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымтада теркәлгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының
08.05.2019 ел, № 342 боерыгы белән
расланды

«Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы вәзгыять турында мәгълүмат җиткерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 16 сентябрендәге 654 номерлы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы вәзгыять турында мәгълүмат җиткерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.9 пунктның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Халыкны эшкә урнаштыруга булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре алучының шәхси эш бланклары формаларын раслау турында» 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2019, 19 март, басылып чыгу номеры: 0001201903190024)»;

1.9 пунктка 16 нчы астөшермәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«[16] алга таба – 19.02.2019 № 90н боерык.»;

1.10 пунктның дүртенче абзацында «26.02.2015 ел, № 125н боерык белән» сүзләрен «19.02.2019 ел, № 90н боерык белән» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлектә:

2.5 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында:

беренче абзацта «26.02.2015 ел, № 125н боерык белән» сүзләрен «19.02.2019 ел, № 90н боерык белән» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гариза мөрәҗәгать итүченең шәхси яки 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә гади электрон имзасы белән таныклана.»;

2.9 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының өченче абзацында «26.02.2015 ел, № 125н боерык белән» сүзләрен «19.02.2019 ел, № 90н боерык белән» сүзләренә алмаштырырга;

2.16 пунктында «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Дәүләт хезмәтен алу өчен, Бердәм порталдагы һәм (яки) Татарстан Республикасы Порталындагы «Шәхси кабинет» аша, гаризаның махсус интерактив формасын тутыру юлы белән, мөрәҗәгать итүчеләргә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны электрон формада тапшыру мөмкинлеге тудырыла;

3 бүлектә:

3.7.2 пунктның өченче абзацында «26.02.2015 ел, № 125н боерык белән» сүзләрен «19.02.2019 ел, № 90н боерык белән» сүзләренә алмаштырырга;

3.8.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8.1. Дәүләт хезмәте электрон рәвештә күрсәтелә:

- халыкның мәшгульлек үзәге рәсми сайтында, Бердәм порталда яки Татарстан Республикасы Порталында, Министрлыкның рәсми сайтында, массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмат урнаштыру юлы белән билгеле булмаган затлар даирәсенә;

- дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза халыкның мәшгульлек үзәкләренә электрон формада, Бердәм порталның яки Татарстан Республикасы Порталының «Шәхси кабинет» аша килгән очракта, мөрәҗәгать итүчеләргә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен Бердәм порталдан яки Татарстан Республикасы Порталыннан файдаланып, электрон формада алу карарын кабул иткән очракта, ул гаризаның электрон формасын тутыра.

Дәүләт хезмәтен Бердәм порталның яки Татарстан Республикасы Порталының «Шәхси кабинет»ы аша электрон формада күрсәтү гаризада сорала торган мәгълүматны, халыкның мәшгульлек үзәге хезмәткәре катнашыннан башка гына, халыкның мәшгульлеге өлкәсендә ведомство мәгълүмат системасында булган белешмәләр нигезендә формалаштырып, аппарат-программа чаралары ярдәмендә автомат рәвештә формалаштыру һәм мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына тапшыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), шулай ук андагы дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр судка кадәр тәртиптә халыкның мәшгульлек үзәгенең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи заты (белгече) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесенә дәгъва белдерү хокукына ия.

Халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Министрлыкка министр исеменә тапшырыла.

Министр карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына шикаять белдерелергә мөмкин.

КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр КФҮ җитәкчесенә белдерелә, КФҮ җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата – КФҮ гамәлгә куючыга.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәне теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче халыкның мәшгульлек үзәге, дәүләт хезмәте күрсәтүче халыкның мәшгульлек үзәге вазыйфаи заты (белгече) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп иткәндә.

5.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның (учреждениенең), шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (белгечнең) яки дәүләт хезмәткәренең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять язмача формада кәгазьдә яисә электрон формада тапшырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган (учреждение), шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган вазыйфаи заты (белгече) яисә дәүләт хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://mtsz.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru), Бердәм порталдан (https://www.gosuslugi.ru) файдаланып җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

КФҮ, КФҮ хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почтадан, «Интернет» челтәреннән файдаланып, КФҮ (http://mfc16.tatarstan.ru) рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы порталыннан

(http://uslugi.tatarstan.ru), Бердәм порталдан (https://www.gosuslugi.ru) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның (учреждениенең), шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (белгечнең) яки дәүләт хезмәткәренең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органда вазыйфаи затның (белгечнең) яисә граждан хезмәткәренең, КФҮ, аның җитәкчесенең яки хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (белгечнең) яки дәүләт хезмәткәренең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (белгечнең) яисә дәүләт хезмәткәренең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Карарны кабул иткән көннән соң бер көн узганчы мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне

кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган (учреждение), КФҮ тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба гражданинга эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.7. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.»;

Татарстан Республикасында хезмәт базарындагы вәзгыять турында мәгълүмат җиткерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта:

«Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре» дигән 1 нче таблицада:

егерме бишенче юлны киләсе редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «Лаеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84378)<br>2-48-12 | 422610, Лаеш ш.,<br>Беренче май ур., 35.<br>Laish.Czn@tatar.ru |

утыз сигезенче юлны киләсе редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «Саба районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84362)<br>2-28-15 | 422060, Байлар Сабасы ш.т.п.,<br>З.Йосыпов ур., 7 й.<br>SZN.Saby@tatar.ru |

«Татарстан Республикасы Хезмәте, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» дигән 2 нче таблицаны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatarstan.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-04 | Klara.Tazetdinova@tatar.ru |
| Хезмәт базарына мониторинг һәм дәүләт хезмәтләре бүлеге | 557-20-93 | Irina.Posokova@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| башлыгы | | |
| Массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлеге башлыгы | 557-20-64 | Rafail.Giniyatultin@tatar.ru»; |

түбәндәге эчтәлекле «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты» дигән 3 таблица өстәргә:

«3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе башлыгы | 264-77-29 | pisma@tatar.ru». |